**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СУКСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422729, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Суксу, ул. Школьная, 9а

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СУЫКСУ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422729, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Суыксу авылы, Мәктәп ур., 9а

тел./факс 8(84365) 61-8-43, e-mail: Suks.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**26 март 2021 ел** **№ 7**

**Суыксу авыл җирлеге территориясендә чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны яисә эшләнмәләрне яндыру урынын һәм ысулларын билгеләү турында**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы «Янгын куркынычсызлыгы турында» Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары нигезендә, Суыксу авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы тотрыклылыкны арттыру максатларында, Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Торак пунктларның гомуми кулланылыштагы җирләрендә, шулай ук торак пунктлар территорияләрендә урнашкан хосусый йорт биләмәләре территорияләрендә учак ягу, махсус билгеләнгән һәм җиһазландырылган урыннардан читтә ризык әзерләү өчен ачык ут куллану, шулай ук әлеге карарның 2 һәм 3 пунктларында билгеләнгән урыннардан һәм ысуллардан тыш, чүп-чар, үлән, яфрак һәм башка калдыклар, материаллар яисә эшләнмәләр яндыру тыела.

2. Түбәндәге территорияләрне чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны яндыру урыны итеп билгеләргә :

| № т/б | Торак пункт исеме | Чүп яндыру урыны | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | Суыксу ав. | торак пункттан төньяк-көнбатыштарак | Башкарма комитет |
| 2. | Ташсу ав. | торак пунктның көньяк-көнбатыш өлешендә | Башкарма комитет |
| 3. | Чәмәк ав. | торак пункттан төньяк-көнбатыштарак | Башкарма комитет |
| 4. | Кече Рәс ав. | торак пункттан көньякта | Башкарма комитет |
| 5. | Олы Рәс ав. | торак пункттан төньяк- | Башкарма |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | көнбатыштарак | комитет |
| 6. | Кондырлы ав. | торак пункттан көньякта | Башкарма комитет |

3. Чүп-чар, үлән, яфраклар һәм башка калдыклар, материаллар яисә эшләнмәләрне яндыру ысулы - ачык учак дип билгеләргә.

4.Ачык ут куллану урыны:

-якындагы объекттан (биналар, корылмалар, төзелмәләр, ачык склад, эскерт) кимендә 50 метр ераклыкта, парклар зонасыннан яисә аерым үсеп килүче ылыслы һәм яфраклы агачлардан яисә агач төркемнәреннән – 100 м булырга тиеш;

-ачык ут куллану урыны тирәсендәге территория корыган агачлардан, коры үләннәрдән, агач кисү калдыкларыннан, башка янучан материаллардан 10 метр радиуста чистартылырга һәм 2 метрдан ким булмаган киңлектәге янгынга каршы, минераллаштырылган полоса белән аерылырга тиеш;

-ачык ут кулланучы зат янгынны сүндерү өчен инвентарь: чиләк, көрәк, су тутырылган мичкә, янгынны локальләштерү һәм бетерү өчен комлы әрҗә, шулай ук янгын саклау бүлеген чакыру өчен мобиль элемтә чарасы белән тәэмин ителергә тиеш.

5. Чүп-чар, үләннәр, яфраклар, агач предметлар һәм башка калдыклар, материалларны яисә эшләнмәләрне яндыруны җилнең тизлеге секундына 5 метрдан артмаганда үткәрергә.

6. Әлеге карар Суыксу авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү чорында үз йогынтысын таратмый.

7. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

8. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Суыксу авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.С.Низамиев